ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ УЛЬЯНКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 нче июль Ульянково авылы № 10

**Ульянково авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына алтынчы чакырылыш депутатларын сайлауларны үткәрүдә матбугат агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегендә яшәүчеләрнең сайлау хокукларында катнашу хокукларын тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставы нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәргәндә һәр сайлау участогы территориясендә басма агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү турындагы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Ульянково авыл җирлеге территориясендә басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеген раслау (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны махсус мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авылҗирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **Ф.А.Сундурова**

Ульянково авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2019 ел, 22 июль, 10 номерлы
Карарына 1 нче кушымта

**Ульянково авыл җирлеге территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына алтынчы чакырылыш депутатларын сайлауларны үткәргәндә агитация материаллары урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге**

| Н/т | Номер СКУ | Махсус урыннар адресы |
|---|---|---|
| 1 | 1622 | ТР, Кайбыч районы, Ульянково авылы Мәктәп урамы, 11а йорт (кибет бинасы) |
| 2 | 1623 | ТР, Кайбыч районы, Корноухово авылы Бутанин урамы, 60 йорт (кибет бинасы) |